ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

20.09.2018г. — с. Майдан — №23

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Мәйдан авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә
КАРАР БИРӘМ:

1. Мәйдан авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны уздыруның уртак инициативасын түбәндәге сорау буенча чыгарырга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:
- Мәйдан авылы юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Тәмте урманчылыгында һәм Ясная Звезда авылында урамнарны яктырту системасын ремонтлау

ӘЙЕ — ЮК.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы — В. В. Михеев